РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
СОРОК-САЙДАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫРЫК-САДАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.01.2025 ел № 1-90

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Кырык Садак авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында карар
проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге Советының 2015 елның 01 июлендәге 1-68 номерлы ( 01.07.2016 № 14-2, 2509.2017 № 34-2, 03.09.2018 № 54-1, 27.08.2019 № 67-1, 05.08.2020 № 92-2, 24.05.2021 №23-1 02.09.2022 № 1-53 18.12.2023 №2-76 карарлары ред) карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставын Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кырык Садак авыл җирлеге Советы законнарына туры китерү максатларында

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге Советы карары проектын (1 нче кушымта) беренче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә::

- эшче төркем җитәкчесе:

Шаһиева Венера Фәрит кызы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кырык Садак авыл җирлеге башлыгы,

- эш төркеме әгъзалары:

Миңнегалиева Флера Галирҗан кызы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре;

Сибгатуллин Әнсар Мансур улы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча Даими комиссиясе рәисе;

Вәлиева Резеда Нәгыйм кызы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппаратының җирлекләр җирле үзидарәсе органнары белән эшләү бүлеге башлыгы;

Сафиуллина Лилия Рәшит кызы – Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы.

3. Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422444, ТР, Буа районы, Кырык Садак авылы, Үзәк ур., 10 йорт, язма рәвештә, карар проекты рәсми басылып чыккан көннән алып 30 көн эчендә, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларда катнашып чыгыш ясау хокукы өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: 422444, ТР, Буа районы, Кырык Садак авылы, Үзәк ур., 10 йорт., эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл Советының 2007 елның 21 маендагы 2-18 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кырык Садак авыл җирлегендә гавами тыңлаулар уздыру турында нигезләмә»дә каралган тәртиптә әлеге проект буенча гавами тыңлауларны 03.02.2025 елда 10.00 сәгатьтә 422444, ТР, Буа районы, Кырык Садак авылы, Үзәк ур., 10 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге башкарма комитеты утырышлар залында үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга (https://buinsk.tatarstan.ru).

5. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проектына тәкъдимнәрне өйрәнергә һәм гомумиләштерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Кырык Садак авыл
җирлеге башлыгы В.Ф.Шаһиева

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының " Кырык Садак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге еставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге Советының 2015 елның 01 июлендәге 1-68 номерлы (01.07.2016 № 14-2, 2509.2017 № 34-2, 03.09.2018 № 54-1, 27.08.2019 № 67-1, 05.08.2020 № 92-2, 24.05.2021 №23-1 02.09.2022 № 1-53 18.12.2023 №2-76 карарлары ред) карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставын Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кырык Садак авыл җирлеге Советы законнарына туры китерү максатларында

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кырык Садак авыл җирлеге Советы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кырык Садак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 1 өлешендәге 12 һәм 42 пунктлары белән түбәндәге редакциядә бәян итәргә һәм өстәргә:

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру»;

«42) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

1.2. 8 статьяның бишенче һәм алтынчы абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

1.3. 11 статьяның 7 өлешендә «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне

һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.;

1.4 16.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.1 статьясы Авыл торак пункты старостасы

1. Җирлектә урнашкан авыл торак пунктында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнарының һәм авыл торак пунктында яшәүчеләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен авыл торак пункты старостасы билгеләнергә мөмкин.

2. Авыл торак пункты старостасы авыл торак пунктының гражданнар җыены тәкъдиме буенча составына әлеге авыл торак пункты кергән җирлек Советы тарафыннан билгеләнә. Авыл торак пункты старостасы шушы авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары йә гражданнар җыены тәкъдим иткән көнгә 18 яшькә җиткән һәм шушы авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак урыны булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.

3. Авыл торак пункты старостасы дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны биләүче зат була алмый, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан яисә муниципаль хезмәт вазыйфасыннан тыш, җирле үзидарә органнары белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә һәм аларга турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрдә була алмый.

4. Авыл торак пункты старостасы итеп түбәндәге зат билгеләнә алмый:

1) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш, дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны биләүче яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче;

2) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган;

3) юкка чыгарылмаган һәм кире алынмаган хөкем ителүе булу;

5. Авыл торак пункты старостасының вәкаләтләре чоры-биш ел.

Авыл торак пункты старостасы вәкаләтләре составына әлеге авыл торак пункты кергән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары буенча, авыл торак пунктындагы гражданнар җыены тәкъдиме буенча, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 10 өлешенең 1-7 һәм $9^2$ пунктларында билгеләнгән очракларда вакытыннан алда туктатыла.

6.Үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен авыл торак пункты старостасы:

1) авыл торак пунктында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр һәм башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итә;

2) халык белән хезмәттәшлек итә, шул исәптән гражданнар җыеннарында, җыелышларында, конференцияләрендә катнашу юлы

белән, мондый чаралар нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиешле мөрәҗәгатьләрне һәм тәкъдимнәрне, шул исәптән муниципаль хокукый актлар проектлары рәвешендә рәсмиләштерелгәннәрен дә җибәрә.;

3) авыл торак пунктында яшәүчеләргә җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре турында мәгълүмат бирә, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан алынган башка мәгълүматны аларга җиткерүдә ярдәм итә;

4) җирле үзидарә органнарына гавами тыңлаулар һәм иҗтимагый фикер алышулар оештыруда һәм уздыруда, аларның нәтиҗәләрен авыл торак пунктында халыкка җиткерүдә ярдәм итә;

5) авыл торак пунктында яшәүчеләр өчен өстенлекле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча инициатив проект кертү турында инициатива белән чыгарга хокуклы;

6) муниципаль берәмлек уставында һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый актында Татарстан Республикасы Законы нигезендә каралган башка вәкаләтләрне һәм хокукларны гамәлгә ашыра.

7. Авыл торак пункты старостасы статусының эшчәнлек гарантияләре һәм башка мәсьәләләре әлеге Устав нигезендә җирлек Советы карары белән билгеләнә.».

1.5. 30 статьяның 6 өлешендәге дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

1.6. 30 статьяның 6.1 өлешендәге 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында «җирлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.7.33 статьяның 1 өлешендә:

14 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

1.8. 40 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11.1 пункт өстәргә:;

«11.1 аның чит ил агенты статусын алуы;»;

1.9. 43 статьяның 7 өлешендәге 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында «җирлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.10. 49 статьяның 1 өлешендә:

4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

7 пунктның дүртенче абзацында «федераль законнарда» сүзләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми

принциплары турында» Федераль Законда, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законында» сүзләренә алмаштырырга;

1.11. VII бүлекне һәм 53 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

1.12. 71 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 71 статья . «Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе»

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек була торган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге Советының 2015 елның 01 июлендәге карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының үзгәртелгән нигезләмәләренең яңа редакциясен хупларга (01.07.2016 № 14-2, 2509.2017 № 34-2, 03.09.2018 № 54-1, 27.08.2019 № 67-1, 05.08.2020 № 92-2, 24.05.2021 №23-1 02.09.2022 № 1-53 18.12.2023 №2-76 карарлары ред.).

3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кырык Садак авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә тапшырырга.

4. Әлеге карар дәүләт теркәвеннән соң «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru/) интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Татарстан Республикасы Буа муниципаль<br>районының Кырык Садак авыл<br>җирлеге башлыгы В.Ф.Шаһиева